Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советы

Кощаково авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

7 апрель, 2026 ел № 9

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә (2017 елның 21 августындагы 16 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 15 номерлы, 2019 елның 23 сентябрендәге 54 номерлы, 2021 елның 28 февралендәге 01.03.2023 номерлы, 2026 елның 15 мартындагы 15 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе хакында нигезләмә нигезендә, карар бирәм:

1.Түбәндәге проект буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә:

- Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге, Званка авылы, Придорожная ур., 10 ж/к адресы буенча урнашкан 16:33:080303:13 кадастр номерлы, 1617 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кощаково авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1) «Кибетләр» файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты.

2. Гавами тыңлауларны үткәрүне оештыручыны - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 24 апрелендән дә соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова